**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в статью 5 Закона Республики Татарстан «Об обеспечении защиты жилищных прав граждан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
22 марта 2018 года

## Статья 1

Внести в часть 1 статьи 5 Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 72-ЗРТ «Об обеспечении защиты жилищных прав граждан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2011, № 10 (I часть); 2012, № 11 (I часть); 2015, № 4; 2016, № 7 – 8; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 27 (часть I), № 94 (часть I) следующие изменения:

1) пункт 13 изложить в следующей редакции:

«13) соблюдением требований правил предоставления, приостановки и ограничения предоставления коммунальных услуг собственникам и пользователям помещений в многоквартирных домах и жилых домах;»;

2) дополнить пунктами 17 – 19 следующего содержания:

«17) соблюдением требований энергетической эффективности и оснащенности помещений многоквартирных домов и жилых домов приборами учета используемых энергетических ресурсов;

18) соблюдением требований правил изменения размера платы за содержание жилого помещения;

19) соблюдением органами местного самоуправления, ресурсоснабжающими организациями, лицами, осуществляющими деятельность по управлению многоквартирными домами, требований к порядку размещения информации в государственной информационной системе жилищно-коммунального хозяйства.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
11 апреля 2018 года
№ 23-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында” Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 22 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында” 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 94 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“13) күпфатирлы йортлар урыннары һәм торак йортлар милекчеләренә һәм алардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү, аларны күрсәтүне туктатып тору һәм чикләү кагыйдәләре таләпләренең үтәлүенә;”;

2) түбәндәге эчтәлекле 17 – 19 пунктлар өстәргә:

“17) энергетика нәтиҗәлелеге һәм күпфатирлы йортлар урыннарының һәм торак йортларның файдаланыла торган энергетика ресурсларын исәпләү приборлары белән җиһазланганлыгы таләпләренең үтәлүенә;

18) торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләре таләпләренең үтәлүенә;

19) дәүләт торак-коммуналь хуҗалык мәгълүмат системасына җирле үзидарә органнары, ресурслар белән тәэмин итү оешмалары, күпфатирлы йортларга идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан мәгълүмат урнаштыру тәртибе таләпләренең үтәлүенә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 11 апрель
№ 23-ТРЗ